РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» апрель, 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 157

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясендә «муниципаль хезмәт турында»гы, 3 октябрь, 2018 ел, 382-ФЗ санлы Федераль законы, 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы «2007 елның 2 мартындагы 25 санлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законына үзгәрешләр кертү турында», Федераль законы, 2008 нче елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2012 елның 28 апрелендәге 112 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 7 бүлекнең 7.1. өлешен түбәндәге эчтәлекле 17,18,19 пунктлары белән тулыландырырга:

«17) Гражданин муниципаль берәмлекнең контроль –хисап органына рәис, рәис урынбасары һәм аудитор вазыйфаларына алына алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта булса (әти-әни, тормыш иптәше, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук тормыш иптәшләренең әти-әнисе, балалары, ир туганнары, кыз туганнары), әлеге территориядәге муниципаль берәмлек контроль – хисап органына рәис, рәис урынбасары һәм аудитор вазыйфаларын алмаштыра алмый»;

«18) Җитәкче булган Муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органында, Район сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатында, әлеге җирле үзидарә органында, Район сайлау комиссиясе аппаратында сайланган

профсоюз органында, күрсәтелгән вазыйфаны үтәгәндә муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый»;

«19) Оештыручысы муниципаль берәмлек булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссияләрендә муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән оешма учредителе яки идарә вәкаләтләре белән муниципаль милектәге акцияләр белән (устав капиталында катнашу өлеше белән) мәнфәгатьләрне бушлай күрсәтү.»

7 бүлекнең 7.4. өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Россия Федерациясе хокукый актлары белән билгеләнгән исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасы башкарган гражданин, муниципаль хезмәттән киткәннән соң ике ел эчендә оешмаларга хезмәт килешүе нигезендә, әгәр әлеге оешманың муниципаль (административ) идарәнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тотышын саклау таләпләре һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча тиешле комиссия ризалыгы белән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаларына кергән булса, һәм (яки) әлеге оешмада эшләр башкарырга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтергә) ай эчендә граждан –хокукый килешү(граждан –хокукый килешүләр ) нигезендә йөз мең сумнан артыкка хезмәт күрсәтә ала.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырылганнан (халыкка таратылганнан) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Советы Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин